**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ТАТАРСКО-САРАЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422633,РТ, Лаишевский район, село
Татарские Саралы, ул.Татарстан, д.17
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422633, РТ, Лаеш районы, Татар
Сараланыавылы, Татарстан урамы, 17
нчейорт
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

---

2024елның «21» мае 162номер

**К А Р А Р**

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган җирле салым суммалары буенча бурыч түләтү өметсез дип танылa, әгәр аларны каплау яисә түләтү түбәндәге очраклар нигезендә мөмкин булмаса:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документла түбәндәгеләр:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) әлеге карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, 500 сумнан артмаган бурыч булу турында салым органының белешмәсе.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 26 апрелендәге 127 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Н.Н. Исхаков**